МИНИСТЕРСТВО
ЗЕМЕЛЬНЫХ И
ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

30.09.2024 Казан ш. 2934-р

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 28.11.2023 № 3366-р Карары белән расланган 2024 елга аларга мөнәсәбәтле салым базасы кадастр бәясе кебек билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының $378^{2}$ статьясының 7 пунктына, “Оешмалар милкенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге № 49-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының $1^{1}$ статьясына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 22.08.2007 № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3.86 пунктына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Россия Федерациясе Салым кодексының $378^{2}$ статьясының 1 пунктындагы 1 подпунктында күрсәтелгән, үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлеген формалаштыру, алып бару, раслау һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында” 2014 елның 21 ноябрендәге № 896 карары белән расланган Россия Федерациясе Салым кодексының $378^{2}$ статьясының 1 пунктындагы 1 подпунктында күрсәтелгән, үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлеген формалаштыру, алып бару, раслау һәм бастырып чыгару тәртибенең 6 нчы пунктына таянып, Салым салу

максатларында биналардан (корылмаларның, каралтыларның) һәм бүлмәләрдән фактик файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карау буенча комиссиянең 25.09.2024 № 10 карары нигезендә:

1. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “2024 елга аларга мөнәсәбәтле салым базасы кадастр бәясе кебек билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлеген раслау турында” 28.11.2023 № 3366-р Карары (Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 22.12.2023 № 3741-р, 15.01.2024 № 14-р, 27.03.2024 № 788-р, 03.06.2024 № 1548-р, 03.07.2024 № 2045-р, 23.08.2024 № 2545-р карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2024 елга аларга мөнәсәбәтле салым базасы кадастр бәясе кебек билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә (алга таба – Исемлек) 483 пунктны төшереп калдырып үзгәреш кертергә.

2. Үзгәрешләр исәпкә алынган Исемлекне электрон формада тиешле тәртиптә Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә җибәрергә.

3. Исемлекне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының рәсми сайтында https://mzio.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан соң булган хокук мөнәсәбәтләренә карый.

5. Әлеге карарны контрольдә тотуны Татарстан Республикасының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **А.Р.Кадыйров**